*Татарстанның халык шагыйре*



*Шәүкәт Галиев*

Шәүкәт Галиев — балалар әдәбиятында шаян шигырләре белән мәгълүм шагыйр. Ул тормышның кызыклы якларын табып балалар белән бүлешә, аларны рәхәтләнеп көлдерә, яхшыны начардан, затлыны затсыздан аерып күрсәтә. Шуңа да шагыйр сурәтләгән хәлләр үтемле булып йөрәккә керә, онытылмый, гел укучыны үзенә тарта.

Шәүкәт Галиев (Шәүкәт Галиулла улы Һидиятуллин) 1928 елның 20 ноябрендә Татарстанның Апае районы Олы Бакырчы авылында туа. Аның малай чагы сугыш елларына туры килә. Шагыйрнең «Әткәйгә хат» (1958) поэмасы сугыш чоры балаларының барысына да мәңгелек һәйкәл булып тора.

1953 елны ул Казанга килә. Кичке урта мәктәпне тәмамлагач, белемен тирәнәйтү өчен Мәскәүдә Язучылар берлегенең югары әдәби курсларында укый. Шул ук вакытта иҗат эше белән дә шөгыльләнә, төрле елларда «Чынлык», «Шалт, Мөхәммәтҗан!», «Фикердәшкә». «Сөенечләрем, көенечләрем» кебек әйбәт шигыр җыентыклары басылып чыга.

Ш. Галиев игелекле хезмәте өчен Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләген (1972) алды, 1982 елда Халыкара бүләк — Х. К. Андерсен исемендәге Почетлы Дипломга һәм Халык шагыйре дигән олы исемгә лаек булды.

# Шәвәлигә ничә яшь ?



- Бу сораугa заманында
- Ул болай җавап биргән :
- -Биш тулырга
- Унбиш минут -
- Дөп-дөресе шул! – дигән.
- Инде яңадан сорыйсы
- Вакыт та җитте менә.
- -Унбиш тулырга
- биш минут ! -
- Ди хәзер җитди генә...
- Әйдә, кемгә күпме кирәк,
- Шул хәтле санасыннар;
- Шәвәли яши берьюлы
- Биш-унбиш арасында!



Шәүкәт Галиевнең әтисе Галиулла , әнисе Бибихәлимә , сеңлесе Нәҗия һәм Шәүкәт. 1940 ел.



Шәүкәт Галиев классташлары белән. 1940 ел



**Шәүкәт Галиевнең район газетасында эшли башлаган вакыты.**

# Балаларның яраткан язучысы



80

Баллада – Италиядән кергән сүз, бию дигәнне аңлата. Баллада - лиро-эпик поэзиянең хикәяләү характерындагы бер төре.

- Бик әүвәлге заманда
- Бакырчыда, Казанда
- Яшәгән ди бер абый,
- Һәм яши ди бер абый,
- Үзе абый,үзе сабый,
- Дөньяга ул
- Шигырь аша карый.
- Һәр баланы җайлый,
- Һәркем аны таный,
- Шигъри теле һаман
- Былбыл булып сайрый.
- Ул – Шәвәли Гали.

